ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «б$^{2}$» һәм «б$^{3}$» пунктчалары өстәргә:

«б$^{2}$) депутатка карата Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу яисә аларның булуы, акча һәм башка кыйммәтләрне саклау, тиешле сайлауларда кандидат буларак теркәлгән чорда чит ил финанс инструментларын биләү һәм (яисә) алардан файдалану фактлары билгеле булу;

б$^{3}$) депутат, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары тарафыннан Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу (аларның булуы), акча һәм башка кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларын биләү һәм (яисә) алардан файдалану;»;

2) 10$^{1}$ статьяда:

а) 1 пунктта тиешле килештә «комиссия» сүзен тиешле килештә «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Депутатның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр әлеге Законның 1 – 2 нче кушымталары нигезендәге белешмәләр формалары

буенча тапшырыла. Җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча депутатның чыгымнары турында, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр алыш-биреш суммасы депутатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган форма буенча тапшырыла.»;

в) 3 пунктның 3 пунктчасында «төп хезмәт (эш) урыны буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

д) 6 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

3) $10^2$ статьяда:

а) исемендә татарча текст үзгәрешсез кала;

б) 1 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

в) 3 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

г) 4 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

4) $10^3$ статьяда:

а) 2 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

б) 5 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

в) 6 пунктның беренче абзацында «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

г) 7 пунктның 6 пунктчасында «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

д) 11 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

е) 12 пунктның 3 пунктчасында «комиссиягә» сүзен «Комиссиягә» сүзенә алмаштырырга;

ж) 14 пунктта «комиссиянең» сүзен «Комиссиянең» сүзенә алмаштырырга;

з) 16 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

и) 18 пунктта «комиссиягә» сүзен «Комиссиягә» сүзенә алмаштырырга;

к) 19 пунктта «комиссиядә» сүзен «Комиссиядә» сүзенә алмаштырырга;

л) 20 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

5) $10^4$ статьяда:

а) 1 пунктның 4 пунктчасында «төп хезмәт (эш) урыны буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 6 пунктта татарча текст үзгәрешсез кала;

6) 1 нче кушымтада татарча текст үзгәрешсез кала;

7) 2 нче кушымтада татарча текст үзгәрешсез кала;

8) 3 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^{1}$ пункт өстәргә:

«$7^{1}$) аларга, шулай ук аларның хатыннарына (ирләренә) һәм балигъ булмаган балаларына карата Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу яисә аларның булуы, акча һәм башка кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларын биләү һәм (яисә) алардан файдалану фактлары билгеле булуга;»;

2) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен чикләүләр һәм тыюлар**

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга федераль законнар нигезендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләр һәм тыюлар кагыла.»;

3) 20 статьяның 3 өлешендә «һәм 19 статьяның өченче өлешеннән» сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 14 мае
№ 35-ТРЗ